**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СОКУРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422622 с. Сокуры,
ул. Школьная , д.1 , помещение 1
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОКУРЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422622 Сокуры авылы,
Школьная урамы, 1 нчы йорт,бина 1
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**2024 елның 28 феврале** **6 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге территориясендә үзәкләштерелгән ташландык суларны агызу буенча гарантияле тәэмин итүчене билгеләү турында**

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законының 12 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге территориясендә үзәкләштерелгән, тиешле һәм өзлексез ташландык суларны агызуны оештыру максатыннан, карар бирәм**:**

1. 2024 елның 1 мартыннан гарантияле оешма статусын, үзәкләштерелгән су агызу системасы өчен, әлеге ресурсларны тәэмин итүче буларак иң күп тоташтырылган абонентлары булган, “Сокуры коммуналь челтәрләре” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә (алга таба - «СКС» ҖЧҖ) бирергә.
2. Сокуры авыл җирлеге территориясенең ташландык суларны чыгару өлешен "СКС" ҖЧҖ гарантияләүче оешмасының эшчәнлек зонасы итеп билгеләргә.
3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Кызыксынучы затларга хәбәр итәргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Н. Газизуллин**